# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

(V чакырылыш)

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

«07 » октябрь 2025 ел № 8 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 30.04.2025 ел, № 15 карарына үзгәрешләр кертү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында»гы 27.05.2003 ел, № 58-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 25.06.2013 № 50-ТРЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 30.04.2025 № 15 карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.03.2025 ел, № 33-ФЗ «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 25.12.2008 ел, № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон, 27.05.2003 ел, № 58-ФЗ «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль закон, 02.03.2007 № 25-ФЗ «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», Татарстан Республикасы кодексының 25.06.2013 № 50-ТРЗ, Татарстан Республикасы Законының 28.07.2004 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы № 45-ТРЗ, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:".

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 30.04.2025 № 15 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә белән "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында»гы 27.05.2003 ел, № 58-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль закон белән, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 25.06.2013 № 50-ТРЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - Башкарма комитет җитәкчесе) вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә.»;

2.2. Нигезләмәнең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясенә конкурс уздыру турында хәбәр басылып чыккан көннән алып 20 календарь көн эчендә әлеге Нигезләмәнең 9 пункты тәртибендә тапшырыла.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

2.3. Нигезләмәнең 16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Конкурс әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны конкурс комиссиясенә тапшыру срогы тәмамланганнан соң 30 көн эчендә үткәрелә.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы З.В. Ильясов

Р.М. Якупов
2-42-05